Хәмидуллина, Р. Өй күрке – мич : [хикәя-дәвамы] / Р. Хәмидуллина // Шәһри Чаллы. – 2026. – № 10 (13 февраль). – Б. 20.



## ХИКӘЯ

Роза Хәмидуллина

# ӨЙ КҮРКЕ – МИЧ



Дәвамы.
Башы 6 февраль санында

«Хәзер барысы да төштә генә кебек. Рәхәт, матур, яшь, бәхетле чаклар иде. Мич, мич шул инде ул. Гомер-гомергә татар авыллары мичле булган, ап-ак күлмәкләрен киеп, өйнең күрке булып, уртада мич утырган. Һәрбер кергән кешене каршы алып, аклык-пакьлек сибеп утыра бит ул мич. Төртеп җибәргәч, утыннарның үзенә бер төрле көй чыгарып, шарт-шорт килеп януы ни тора. Кылны йөзгә бүлергә торган киленбикәләрнең дә бит алмалары шул ялкын очкыннары кебек кызарып яна. Ә ул ут кызуында пешкән ризыкларны күр әле син, ләвеш, коймак, кабартмаларны ашап туймаслык. Каен, имән утынының ялкынын сеңдереп пешкән камыр гына шулай тәмле, хуш исле була». Тагын уйларына батып киткән Мәдинәне улы тынычландырырга ашыкты:

– Кайгырма, әнкәй, бу юлы да Норлаттан алып киләм миччене.

– Теге Рухулла оста малаен әйтәсең мәллә? Бик мактыйлар үзен, җыйнак, матур чыгара, диләр. Ярар, ярар кем булса да булсын, матур итеп пешерсә, шул җиткән, улым. ИншәАллаһ, бик яхшы булыр иде.

Иртәгесен иртүк, мотоциклына утырып, мичче килеп җитте. Мәдинә аны ишек алдында ук сынаулы карашы белән каршы алды. Уртача гына буйлы, куе кара чәчләрен өскә тырпайтып тараган, тулы битле егет. Болай, ярыйсы, ыспай гына күренә. Исәнләшеп, танышканнан соң:

– Карале, бик яшь күренәсең, синмени инде ул бик мактаулы мич чыгаручы, Рухулла малае? – дип, өйгә әйдәде Мәдинә.

Мичче, оялгандай булып:

– Ул кадәр үк кирә-керешкә мактамагыз инде, әби, – дип, аның артыннан өйгә үтте.

– Кешедән ишеткәнне генә әйтәм. Халә киленгә дә син чыгаргансың икән, Дамир кодага да... Мактап туя алмыйлар менә, мин сиңа әйтим, – дип, мичченең бер алдына бер артына төште Мәдинә.

Мичче аз сүзле иде. Сүтеп аткан мич урынында озак таптанып торырга исәбе юк иде аның.

– Әби, кода-киленнәрне калдырып тор әле хәзергә, үзеңнең мичеңне ничек чыгарыйк соң? – диде.

Мәдинә дә сүзне кыска тотты:

– Улым, искесенә караганда кечерәк булса да ярый. Иске мичкә алты таба кирә иде, монысына дүрт таба сыйса да җиткән. – Сөйләнә-сөйләнә почмак якка үтте. – Мичнең авызы тәрәзәгә карасын, улым. Мич кашы да кирәк, чиләк белән бәрәңге кереп утырырлык урын калдырсаң да менә бу яктан..., – дип тезеп китте.

– Әби, аларын соңрак күрсәтерсең яме. Әлегә.., – дип, бер аяк үкчәсендә генә идәнне боргычлап бөтерелде дә, кинәттән, – магнитофоныгыз бармы сезнең? – дип сорап куйды.

Мәдинәнең исе-акылы китте.

– Ялгыш ишеттем, ахры, нәрсә дисең улым, магнитафун дисеңме? – Үзе җавабын да көтеп тормый, кулларын билләренә таянып, бөтен буйга егетнең алдына чыгып басты. – Син, улым, чынлап торып миччеме соң? Нәрсәгә кирәк булды сиңа ул нәмәстә? – Егетнең берсүзсез көлемсерәп карап торуын күреп, оныкларына: – Алия, Алинә кызым, абыегыз магнитафун кирәк ди, китерегез әле, – диюдән уза алмады, ә үзе тагын бер кабатлады: – Улым, ни эшләмәкче буласың аның белән?

Мичче сүзгә еракка китмәде:

– Оныкларың нишлиләр соң, әби?

– Нишлиләр дип... бииләр инде...

– Ә-ә, шулаймы? Мин дә биим.

Мичче магнитофонны ачып җайлырак урынга урнаштырып куйды да мич калыпларга керешә. Талгын гына көй яңгырый, мичче, эшен белеп, җиренә җиткереп эшләгәнгә охшый, күз тимәсен, бик җитез кылана, кулында шактый авыр кирпечләрне туп шикелле биетә. Кодасы изменә ясап, өлгертеп бара алса ярый да бит инде, – диеп тә уйлап куйды әле Мәдинә.

Дәвамы бар

Telegramда безнең төркем
shahrichally

ВКонтактеда безнең төркем
shahrichalli

Одноклассникида безнең төркем
shrichally.gazetasy